ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘРКӘТӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
БЕРКЕТ-КЛЮЧЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

423106, БӘРКӘТӘ АВЫЛЫ,
ЛЕНИН УРАМЫ, ЙОРТ 76 “а”

тел.+7(84396)
2-64 -66
тел./факс
+7(84396) 2-64-66

423106, СЕЛО БЕРКЕТ- КЛЮЧ,
УЛИЦА ЛЕНИНА, ДОМ 76 «а»

№127 26.12.2024 ел

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 7 февралендәге №107 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Бәркәтә авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 7 февралендәге №107 карарына (Советның 11.06.2019 елгы 116 номерлы, 30.09.2021 елгы 36 номерлы, 23.08.2024 елгы 115 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктта:

- 2 абзацның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән салым салу объектларында урнашканнары, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата».
- 3 абзацның 1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән

муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.М.Сибгатуллин